МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

18.05.2026 Казан ш. 1228-р

Газ бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының Алексеевск, Спас (өлешчә), Чистай (өлешчә) муниципаль районнары территориясендә газ бүлгеч челтәрләрнең саклау зонасы чикләрен раслау турында» 05.11.2014 № 2401-р карарына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ хатын исәпкә алып (13.05.2026 № 02А-04/1186) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып:

1. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милке булган, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының Алексеевск, Спас (өлешчә), Чистай (өлешчә) муниципаль

районнары территориясендә газ бүлгеч челтәрләрнең саклау зонасы чикләрен раслау турында» 05.11.2014 № 2401-р карары (алга таба - № 2401-р Карар) белән урнаштырылган 53534 инвентарь номерлы, 16:05-6.241 реестр номерлы бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасын трасса үзгәртелеп газүткәргеч үзгәртеп корылу сәбәпле территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, үзгәртергә. Бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасы озынлыгы гомуми мәйданы 25976 +/- 1410 кв.м.лы территория рәвешендә 6494 м.ны тәшкил итә.

2. Инвентарь номеры 53534 булган газ бүлгеч газүткәргечне эксплуатацияләү срогында газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлгеч челтәрләрне саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә 1 пунктның 1.1. подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, № 2401-р Карарга үзгәреш кертергә:

«1.1. «Чистопольгаз» ЭПУ газ бүлү газүткәргече, әлеге Боерыкның 1 нче кушымтасы нигезендәге инвентарь номерлары белән, Алексеевск муниципаль районы территориясендә, озынлыгы 673,924 км, гомуми мәйданы 2,742749 кв. км (2742749 кв. м) булган территория рәвешендә, һәм 2014 елның 5 августыннан 2014 елның 10 сентябренә кадәр кадәр «Земля» ААҖ башкарган һәм 2024 елның 10 октябрендә «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ белән килештерелгән җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зонасы картасында (планында) булган белешмәләргә ярашлы;».

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.Ә.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**